**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО**

**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

16.06.2025 ел №10

**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Яңа Әлем авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Актаныш таннары» газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында (http://pravo.tatarstan.ru), ул кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе М.М. Исламов